| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

2023 елның 10 апреле № 16

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарларын гамәлдән чыгару турында

Гамәлдәге законнар нормаларына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарларын гамәлдән чыгарырга:

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мелкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр турында белешмәләр бирү турында, хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, мөлкәте һәм мелкәт характерындагы йөкләмәләре турында» 2016 елның 27 апрелендәге 34 номерлы;

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 34 номерлы карары белән расланган Туктар-Урдаласы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Туктар-Урдаласы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мелкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 1 июнендәге 12 номерлы.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар - Урдаласы авылы, Совет урамы, 98 йорт административ бинада, Совет урамы, 103 йорт мәдәният йорты бинасында, Карагай авылы, Тельман урамы, 31 йорт КФҮ бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Ә.Әхмәтова